ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 май, 2021 ел №7/11

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 16 июлендәге 33/7 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 20 статьясы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 49 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 16 июлендәге 33/7 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2009 елның 23 декабрендәге 44/14, 2010 елның 15 ноябрендәге 4/13, 2013 елның 29 августындагы 26/15 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8. Конкурста катнашырга теләгән гражданнар конкурс комиссиясенә тапшыралар:

1) конкурс комиссиясе рәисе исеменә шәхси гариза;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетаны фотография белән;

3) паспорт яки аны алмаштыручы документ;

4) кирәкле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификацияне раслаучы документлар:

- хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадр хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән мәгълүматлар;

- һөнәри белем, шулай ук гражданин теләге буенча, өстәмә һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документ;

5) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыру булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

6) муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, башка норматив хокукый актларда каралган башка документлар.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф. Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев